ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**09.09.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2439**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 11 июлендәге 1892 номерлы карары белән расланган, гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантларны алучыларны сайлап алуны уздыру турында» 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларыннан субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 20 мартындагы 210 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 11 июлендәге 1892 номерлы карары белән расланган, гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында

оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: ««Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен юл йөрү билеты һәм балалар юл йөрү билеты буенча җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә бәйле і-транспорт оешмасына бирелә торган алынмаган керемнәрне компенсацияләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә»;

1.2. Нигезләмәнең 4.7 пунктындагы унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - сайлап алуда катнашучының гамәлгә кую документлары нигезендә сайлап алуда катнашучы башкарырга хокуклы эшчәнлекнең төп төрләре исемлеге»;

1.3. Нигезләмәнең 4.17 пунктындагы е) пунктчасын төшереп калдырырга;

1.4. Нигезләмәнең 4.34 пунктындагы е) пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru ) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин